**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**18.03.2019 ЕЛ** Болгар **№ 177**

**“Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының “ Балаларны исәпкә кую һәм аларны мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган (балалар бакчалары) белем бирү оешмаларына укырга кабул итү” буенча муниципаль хезмәтләрдән файдаланганда административ регламентны раслау турында”гы 2015 елның 18 маендагы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”**

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының “Балаларның исәпкә кую һәм аларны мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына укырга кабул итү” буенча муниципаль хезмәтләрдән файдаланганда Административ регламентның якынча формасына үзгәрешләр кертү турында”гы 2015 елның 10 мартында расланган 1389/15нче боерыгын үтәү турындагы ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының 26.12.2018 елдагы 1975/18нче боерыгын үтәү һәм гамәлдәге законга туры китерү максатында Спас муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.Татарстан Республикасының Спас муниципаль районы Башкарма комитетының “Балаларны исәпкә кую һәм аларны мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган (балалар бакчалары) белем бирү оешмаларына укырга кабул итү” муниципаль хезмәтләрдән файдаланганда административ регламентны раслау турында”гы 2015 елның 18 маенда расланган “Балаларны исәпкә кую һәм аларны мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган (балалар бакчалары) белем бирү оешмаларына укырга кабул итү” буенча муниципаль хезмәтләрдән файдаланганда Административ регламентка түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә

1.1. 3.3.4 пункт астын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

“Льготаның гамәлдәге вакыты чыкканнан соң, Гариза белән мөрәҗәгать итүче Оешмага чираттан тыш яки беренче чиратта кабул итүгә булган хокукын расларга тиеш.”;

1.2. 3.4.3 пункт астының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Уку елы дәвамында, буш урыннар булган очракта, Оешма Административ регламентның 3 пунктында каралганча, тиешле тәртиптә тулыландырыла;

1.3. 3.4.3 пункты астын алып ташларга;

1.4. 3.4.5 пункты астында “5 эш көненнән дә артмаска тиеш” сүзен “1 эш көненнән дә артмаска тиеш” сүзе белән алмаштырырга;

1.5. 3.5.3 пункты астының икенче абзацында “3 ай дәвамында” сүзен “Бер ай дәвамында” сүзе белән алмаштырырга;

1.6. 3.5.4 пункты астының беренче абзацын түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга:

“Баланы бакчага кабул итү датасы гариза бирүченең юлламадан баш тарткан көннән алдарак булмаган датага алыштырыла.”;

1.7. 3.5.3 пункты астынының беренче абзацында “Оешма җитәкчесе

Системада гаризага “Килмәде” статусы бирә” сүзен “Системадагы гаризага “Килмәде” статусы бирелә” дигән сүзләр белән алыштырырга;

1.8. 3.5.6 пунктындагы беренче абзацны түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга:

“Расланган очракта баланы бакчага кабул итү датасы гариза бирүченең юлламадан баш тарткан көннән алдарак булмаган датага алыштырганда муниципаль хезмәтләрдән файдалануга булган ихтыяҗ да раслана.”;

1.9. 3.5.8 пунктының икенче абзацында “3 айлык срокка” сүзен “бер айлык срокка сүзе белән алыштырырга”;

1.10. 3.5.9 пунктының беренче абзацын түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга:

“Расланган очракта баланы бакчага кабул итү датасы гариза бирүченең юлламадан баш тарткан көннән алдарак булмаган датага алыштырганда муниципаль хезмәтләрдән файдалануга булган ихтыяҗ да раслана.”.

2. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Е.А.Афоньшинага йөкләргә.

3. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Татарстан Республикасының Спас муниципаль
районы Башкарма комитеты җитәкчесе В.А.Осокин.